БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«31» 10 2025ел

**КАРАР**
№ 300

Социаль инфраструктураның муниципаль объектыннан файдалану турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясе хакында

"Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында" 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясе хакындагы Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясе составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.С.Галимуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
20 25 елның « 31 » 10
300 номерлы карарына
1 нче кушымта

Балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яисә бетерү хакында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясе турында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча җирле үзидарә органнары комиссиясен төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә түбәндәгеләргә таянып эш итә:

Россия Федерациясе Конституциясе,

Федераль конституциячел законнар,

Федераль законнар,

Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләре,

Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре,

Татарстан Республикасы һәм җирле үзидарә органының норматив хокукый актлары,

Әлеге Нигезләмәгә.

3. Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

а) балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен, муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзүне Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган критерийлар нигезендә бәяли.

б) балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзелү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү хакында бәяләмә әзерли;

в) ТР Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган критерийлар нигезендә муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяли;

г) муниципаль оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү хакында бәяләмә әзерли.

4. Үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне хәл иткәндә үзенә йөкләнгән функцияләрне башкару комиссиясе карала торган мәсьәләләр буенча карар кабул итү өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга, аларны тапшыру срокларын билгеләргә, шулай ук эш төркемнәре төзергә хокуклы.

5. Комиссия составына түбәндәге затлар керә:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты вәкилләре

- "Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе"

- ТР Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы

- Балалар өчен социаль инфраструктура объекты урнашкан тиешле җирлек башлыгы.

6. Комиссияне комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче, мәсьәләләр буенча фикер алышуда коллегиальлекне тәэмин итүче, бурычларны бүлешүче һәм комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирүче рәис җитәкли. Комиссия әгъзаларының минималь саны, комиссия рәисен дә исәпкә алып, 7 кеше тәшкил итә. Рәис булмаган очракта аның функцияләрен комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия эшчәнлегенең төп формасы комиссия утырышларыннан гыйбарәт. Комиссия балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында яки балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яисә бетерү, муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне уздыру турында гариза кергәч утырышлар үткәрә.

Комиссия утырышлары күндезге формада, шул исәптән видео-конференц-элемтә режимыннан файдаланып уздырылырга мөмкин.

Комиссия утырышында аның составының кимендә яртысы катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карала торган мәсьәлә буенча карарны утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы нигезендә, ачык тавыш бирү юлы белән кабул итә. Читтән торып тавыш бирү сораштыру кәгазенә кул кую юлы белән үткәрелә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Нигезләнгән һәм объектив карар кабул итү максатларында комиссия утырышларында катнашу өчен экспертлар һәм җирле үзидарәнең кызыксынган башка органнары вәкилләре чакырылырга мөмкин. Комиссия әгъзалары, экспертлар һәм башка кызыксынган затлар, җирле үзидарә органнары вәкилләре комиссия эшендә ирекле һәм түләүсез нигездә катнашалар.

8. Комиссия балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү, балалар өчен социаль инфраструктураны барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты билгеләгән документлар исемлеге нигезендә, аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяли.

9. Комиссия эше йомгаклары буенча тиешле бәяләмә (уңай яисә тискәре) рәсмиләштерелә, ул комиссиянең утырышта катнашучы әгъзалары тарафыннан имзалана.

Комиссиянең кабул ителгән карар белән килешмәгән әгъзасы үзенең махсус фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул комиссия бәяләмәсенә кушымта итеп бирелә.

Күрсәтелгән бәяләмә комиссия утырышын уздырган көннән алып 20 эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия тарафыннан әзерләнә һәм рәсмиләштерелә.

10. Балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү,

оешма тарафыннан аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү турындагы бәяләмәдә балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү, балалар өчен социаль инфраструктураны барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү тәртибенең 9 пункты нигезендә билгеләмәләр күрсәтелә.

Муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү хакындагы бәяләмәдә балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү, балалар өчен социаль инфраструктураны барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү тәртибенең 10 пункты нигезендә билгеләмәләр күрсәтелә.

Комиссиянең әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы "б" һәм "г" пунктчаларында каралган бәяләмәләре, дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

11. Балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү, балалар өчен социаль инфраструктураны барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү тәртибенең 12 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләргә таянып комиссия тискәре бәяләмә бирә.

12. Балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек булган объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү, балалар өчен социаль инфраструктураны барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү тәртибенең 13 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләргә таянып комиссия уңай бәяләмә бирә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
20 25 елның « 31 » 10
300 номерлы карарына
2 нче кушымта

Балалар өчен социаль инфраструктураның муниципаль милек объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Галимуллин Ильшат Солтан улы | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары-комиссия рәисе |
| Гайнетдинов Илһам Фидәил улы | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - комиссия рәисе урынбасары |
| Заһидуллин Рөстәм Рафис улы | Балтач районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе, комиссия әгъзасы |
| Мөхәрләмов Ренат Камил улы | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе»МКУ башлыгы |
| Фәтхетдинов Илвир Мөбарәк улы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе-комиссия әгъзасы |
| Гатиятуллина Лилия Шакир кызы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе - комиссия әгъзасы |
| | тиешле авыл җирлеге башлыгы-комиссия әгъзасы |